**IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ II СЕССИЯСЕ**

**К А Р А Р № 11**

Мөслим «13» ноябрь 2020 ел

**Мөслим муниципаль районы Советының «2020 елга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) раслау турында» 2020 елның 13 февралендәге 170 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Уставының 32 статьясына таянып, күчемсез милек объектларына муниципаль милек хокукын теркәү һәм суд тәртибендә муниципаль милек хокукын тану белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Мөслим муниципаль районы Советының «2020 елга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) раслау турында» 2020 елның 13 февралендәге 170 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Әлеге карарга кушымта нигезендә бирелгән түбәндәге объектларны Мөслим муниципаль районы муниципаль милкен 2020 елга хосусыйлаштыруның фараз планына (программасына) кертергә һәм расларга.

2. Мөслим муниципаль районының Мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына күрсәтелгән мөлкәтне хосусыйлаштыру ысулын билгеләүне йөкләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мөслим муниципаль районы Башлыгы урынбасары А.М. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы Советы Рәисе Р.Х. Муллин

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль
районы Советының
2020 елның «13» ноябрендәге
11 нче номерлы карарына
кушымта

2020 елга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы)

1. 161,2 кв.м мәйданлы фельдшер-акушерлык пункты бинасы, адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Мөслим районы, Тойгелде авыл җирлеге, Тойгелде авылы, Үзәк ур., 4а йорт;

2. 425,8 кв. м. мәйданлы Тойгелде балалар бакчасы бинасы, адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Мөслим районы, Тойгелде авылы, Үзәк ур., 6 йорт;

3. 376 кв.м мәйданлы Симәк балалар бакчасы бинасы, адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Мөслим районы, Симәк авыл җирлеге, Симәк авылы;

4. 672 кв.м мәйданлы Тат.Бүләр балалар бакчасы бинасы, адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Мөслим районы, Тат. Бүләр авылы, Яшьләр ур., 12 йорт.

5. 268 кв.м мәйданлы Яңа Усы балалар бакчасы бинасы, адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Мөслим районы, Яңа Усы авылы, Совет ур., 32 йорт.

6. 156 кв.м мәйданлы Яңа Сәет мәктәбе бинасы, адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Мөслим районы, Исәнсеф авыл җирлеге, Яңа Сәет авылы, Урак һәм Чүкеч ур., 30 йорт.

7. 607 кв.м мәйданлы Әмәкәй балалар бакчасы бинасы, адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Мөслим районы, Әмәкәй авыл җирлеге, И.Фәррахов ур., 35 йорт.

8. 621,5 кв.м мәйданлы торак булмаган сыер абзары бинасы, кадастр номеры: 16:29:130301:122, адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Мөслим районы, Октябрь авыл җирлеге, Октябрь авылы.

9. 224,4 кв.м мәйданлы мәктәп бинасы, адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Мөслим районы, Исәнсеф авыл җирлеге, Исәнсеф авылы, Г.Вәҗетдинов ур., 8а йорт.